# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О народных художественных промыслах

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
6 июня 2024 года

### Статья 1. Предмет регулирования настоящего Закона

1. Настоящий Закон регулирует отношения в области народных художественных промыслов на территории Республики Татарстан.

2. Участниками отношений в области народных художественных промыслов являются граждане и юридические лица любых организационно-правовых форм и форм собственности.

### Статья 2. Правовое регулирование отношений в области народных художественных промыслов

Правовое регулирование отношений в области народных художественных промыслов основывается на положениях Конституции Российской Федерации, Конституции Республики Татарстан, Закона Российской Федерации от 9 октября 1992 года № 3612-I «Основы законодательства Российской Федерации о культуре» и осуществляется Федеральным законом от 6 января 1999 года № 7-ФЗ «О народных художественных промыслах» (далее – Федеральный закон), другими федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, настоящим Законом и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

### Статья 3. Основные понятия

1. Для целей настоящего Закона под Реестром мастеров народных художественных промыслов Республики Татарстан (далее – Реестр мастеров) понимается информационная система, содержащая сведения о мастерах народных художественных промыслов, осуществляющих свою деятельность в качестве индивидуального предпринимателя либо в качестве физического лица, применяющего специальный налоговый режим «Налог на профессиональный доход».

2. Иные понятия, используемые в настоящем Законе, применяются в том же значении, в каком они определены в Федеральном законе.

Статья 4. **Полномочия органов государственной власти Республики Татарстан в области народных художественных промыслов**

1. К полномочиям Государственного Совета Республики Татарстан в области народных художественных промыслов относятся:

1) законодательное регулирование отношений в области народных художественных промыслов;

2) осуществление контроля за исполнением законов Республики Татарстан в области народных художественных промыслов;

3) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

2. К полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан в области народных художественных промыслов относятся:

1) издание нормативных правовых актов в области народных художественных промыслов;

2) утверждение государственных программ Республики Татарстан, содержащих мероприятия в области народных художественных промыслов;

3) оказание поддержки народным художественным промыслам (за исключением организаций народных художественных промыслов, перечень которых утверждается уполномоченным Правительством Российской Федерации федеральным органом исполнительной власти);

4) утверждение порядка отнесения изделий, изготовляемых на территории Республики Татарстан, к изделиям народных художественных промыслов;

5) утверждение положения о Художественно-экспертном совете по народным художественным промыслам;

6) установление мест традиционного бытования народных художественных промыслов;

7) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

3. К полномочиям органа исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченного в области народных художественных промыслов (далее – уполномоченный орган), относятся:

1) принятие мер по сохранению, возрождению и развитию народных художественных промыслов на территории Республики Татарстан;

2) утверждение положения о Реестре мастеров, которое содержит порядок формирования и ведения Реестра мастеров, порядок принятия решения о включении мастеров народных художественных промыслов в Реестр мастеров и порядок исключения их из Реестра мастеров;

3) принятие решения о включении мастеров народных художественных промыслов в Реестр мастеров и решения об исключении их из Реестра мастеров;

4) обеспечение ведения информационных систем в области народных художественных промыслов, в том числе с привлечением подведомственных уполномоченному органу организаций;

5) направление сведений в государственный реестр мест традиционного бытования народных художественных промыслов, государственный реестр образцов изделий народных художественных промыслов признанного художественного достоинства;

6) представление в Федеральный экспертный совет по народным художественным промыслам образцов изделий народных художественных промыслов в целях регистрации их в качестве образцов изделий народных художественных промыслов признанного художественного достоинства;

7) формирование и утверждение состава Художественно-экспертного совета по народным художественным промыслам;

8) осуществление иных полномочий, предусмотренных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

4. Органы государственной власти Республики Татарстан вправе оказывать:

1) поддержку организациям народных художественных промыслов, перечень которых утверждается уполномоченным Правительством Российской Федерации федеральным органом исполнительной власти;

2) финансовую, информационную, консультационную, организационную поддержку и иные меры поддержки, предусмотренные законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан, мастерам народных художественных промыслов, сведения о которых включены в Реестр мастеров.

Статья 5. **Участие органов местного самоуправления в сохранении, возрождении и развитии народных художественных промыслов**

1. Органы местного самоуправления городского поселения, муниципального района, городского округа участвуют в сохранении, возрождении и развитии народных художественных промыслов соответственно в городском поселении, муниципальном районе, городском округе.

2. Органы местного самоуправления городского поселения, муниципального района, городского округа вправе оказывать мастерам народных художественных промыслов, сведения о которых включены в Реестр мастеров, финансовую, информационную, консультационную, организационную поддержку и иные меры поддержки, предусмотренные законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан, уставами муниципальных образований.

Статья 6. **Организации народных художественных промыслов**

1. Основной задачей деятельности организаций народных художественных промыслов является сохранение, возрождение и развитие традиций народных художественных промыслов.

2. К организациям народных художественных промыслов относятся организации (юридические лица) любых организационно-правовых форм и форм собственности, в объеме отгруженных (подлежащих реализации путем поставки или иной продажи либо обмена) товаров собственного производства (работ, услуг, выполненных, оказанных своими силами) которых изделия народных художественных промыслов, по данным федерального государственного статистического наблюдения за предыдущий год, составляют не менее 50 процентов.

3. Сведения об осуществляющих деятельность на территории Республики Татарстан организациях народных художественных промыслов размещаются в открытом доступе на официальном сайте уполномоченного органа в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

Статья 7. **Мастер народного художественного промысла**

1. Мастер народного художественного промысла вправе осуществлять свою деятельность на условиях трудового договора или гражданско-правового договора с юридическим лицом либо с индивидуальным предпринимателем.

2. Мастер народного художественного промысла вправе осуществлять свою деятельность в качестве индивидуального предпринимателя.

3. Мастер народного художественного промысла вправе осуществлять свою деятельность в качестве физического лица, применяющего специальный налоговый режим «Налог на профессиональный доход», с учетом положений Федерального закона.

4. Сведения о мастерах народных художественных промыслов, осуществляющих свою деятельность в качестве индивидуального предпринимателя либо в качестве физического лица, применяющего специальный налоговый режим «Налог на профессиональный доход», включаются в Реестр мастеров.

5. Сведения, содержащиеся в Реестре мастеров, размещаются в открытом доступе на официальном сайте уполномоченного органа в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» (за исключением сведений, доступ к которым ограничен в соответствии с законодательством Российской Федерации).

Статья 8. **Отнесение изделий, изготовляемых на территории Республики Татарстан, к изделиям народных художественных промыслов**

1. Отнесение изделий, изготовляемых на территории Республики Татарстан, к изделиям народных художественных промыслов осуществляется на основе решения Художественно-экспертного совета по народным художественным промыслам, принимаемого по результатам рассмотрения представленных типовых образцов и уникальных изделий народных художественных промыслов. Такое решение принимается в соответствии с перечнем видов производств и групп изделий народных художественных промыслов, который утверждается в порядке,

устанавливаемом уполномоченным Правительством Российской Федерации федеральным органом исполнительной власти.

2. Решение Художественно-экспертного совета по народным художественным промыслам, принимаемое по вопросам отнесения изделий к изделиям народных художественных промыслов, размещается в открытом доступе на официальном сайте уполномоченного органа в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» (за исключением сведений, которые содержатся в таком решении и доступ к которым ограничен в соответствии с законодательством Российской Федерации).

Статья 9. **Художественно-экспертный совет по народным художественным промыслам**

1. Художественно-экспертный совет по народным художественным промыслам осуществляет свою деятельность на основе положения о Художественно-экспертном совете по народным художественным промыслам, утверждаемого Кабинетом Министров Республики Татарстан на основе типового положения о художественно-экспертном совете по народным художественным промыслам, утверждаемого уполномоченным Правительством Российской Федерации федеральным органом исполнительной власти.

2. Художественно-экспертный совет по народным художественным промыслам по результатам рассмотрения изделий:

1) принимает решение об их отнесении к изделиям народных художественных промыслов;

2) осуществляет экспертное сопровождение деятельности в области народных художественных промыслов;

3) принимает решение о направлении в Федеральный экспертный совет по народным художественным промыслам образцов изделий народных художественных промыслов в целях регистрации их в качестве образцов изделий народных художественных промыслов признанного художественного достоинства;

4) выполняет иные функции, определенные положением о Художественно-экспертном совете по народным художественным промыслам.

Статья 10. **Места традиционного бытования народных художественных промыслов**

1. Места традиционного бытования народных художественных промыслов устанавливаются Кабинетом Министров Республики Татарстан в соответствии с утвержденными Правительством Российской Федерации правилами установления мест традиционного бытования народных художественных промыслов и утвержденным уполномоченным Правительством Российской Федерации федеральным органом исполнительной власти перечнем видов производств и групп изделий народных художественных промыслов.

2. Сведения о местах традиционного бытования народных художественных промыслов Республики Татарстан размещаются в открытом доступе на

официальном сайте уполномоченного органа в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» (за исключением сведений, доступ к которым ограничен в соответствии с законодательством Российской Федерации).

3. Сведения о местах традиционного бытования народных художественных промыслов Республики Татарстан подлежат включению в государственный реестр мест традиционного бытования народных художественных промыслов, порядок формирования и ведения которого устанавливается уполномоченным Правительством Российской Федерации федеральным органом исполнительной власти.

Статья 11. **Признание утратившими силу отдельных законодательных актов (положений законодательных актов) Республики Татарстан**

Признать утратившими силу:

1) Закон Республики Татарстан от 12 января 2005 года № 3-ЗРТ «О народных художественных промыслах и ремеслах» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 1 (I часть);

2) Закон Республики Татарстан от 17 февраля 2006 года № 13-ЗРТ «О внесении изменения в статью 6 Закона Республики Татарстан «О народных художественных промыслах и ремеслах» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 2 (I часть);

3) Закон Республики Татарстан от 31 марта 2010 года № 14-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О народных художественных промыслах и ремеслах» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2010, № 3);

4) статью 16 Закона Республики Татарстан от 12 июня 2014 года № 53-ЗРТ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 6 (II часть);

5) Закон Республики Татарстан от 5 марта 2018 года № 7-ЗРТ «О внесении изменений в статью 4 Закона Республики Татарстан «О народных художественных промыслах и ремеслах» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 22 (часть I).

Статья 12. **Вступление в силу настоящего Закона**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
18 июня 2024 года
№ 46-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Халык сәнгать һөнәрләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 6 июнендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала.
2. Гражданнар һәм теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвешендәге һәм милек рәвешендәге юридик затлар халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендәге мөнәсәбәтләрдә катнашучылар була.

2 статья. **Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» 1992 елның 9 октябрендәге 3612-I номерлы Россия Федерациясе Законы нигезләмәләренә таяна һәм «Халык сәнгать һөнәрләре турында» 1999 елның 6 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

3 статья. **Төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында Татарстан Республикасы халык сәнгать һөнәрләре осталары реестры (алга таба – Осталар реестры) дигәндә үз эшчәнлеген индивидуаль эшкуар йә «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик зат буларак гамәлгә ашыручы халык сәнгать һөнәрләре осталары турында белешмәләр булган мәгълүмат системасы аңлашыла.

2. Әлеге Законда кулланыла торган башка төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

4 статья. **Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендәге Татарстан Республикасы законнары үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2. Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә норматив хокукый актлар чыгару;

2) халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендәге чаралар булган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын раслау;

3) халык сәнгать һөнәрләренә (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган халык сәнгать һөнәрләре оешмаларыннан тыш) ярдәм күрсәтү;

4) Татарстан Республикасы территориясендә әзерләнә торган эшләнмәләрне халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләренә кертү тәртибен раслау;

5) Халык сәнгать һөнәрләре сәнгать-эксперт советы турындагы нигезләмәне раслау;

6) халык сәнгать һөнәрләре традицион булган урыннарны билгеләү;

7) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

3. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендәге вәкаләтле органы (алга таба – вәкаләтле орган) вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы территориясендә халык сәнгать һөнәрләрен саклау, торгызу һәм үстерү чараларын күрү;

2) Осталар реестры булдыру һәм аны алып бару тәртибе, халык сәнгать һөнәрләре осталарын Осталар реестрына кертү турында карар кабул итү тәртибе һәм аларны Осталар реестрыннан чыгару тәртибе булган Осталар реестры хакындагы нигезләмәне раслау;

3) халык сәнгать һөнәрләре осталарын Осталар реестрына кертү турында карар һәм аларны Осталар реестрыннан чыгару хакында карар кабул итү;

4) халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә мәгълүмат системаларын, шул исәптән вәкаләтле орган буйсынуындагы оешмаларны җәлеп итеп, алып баруны тәэмин итү;

5) халык сәнгать һөнәрләре традицион булган урыннар дәүләт реестрына, халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләренең сәнгати кыйммәте танылган үрнәкләре дәүләт реестрына белешмәләр җибәрү;

6) халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләре үрнәкләрен аларны халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләренең сәнгати кыйммәте танылган үрнәкләре буларак теркәү максатларында Халык сәнгать һөнәрләре федераль эксперт советына тапшыру;

7) Халык сәнгать һөнәрләре сәнгать-эксперт советы составын формалаштыру һәм раслау;

8) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләрне күрсәтергә хокуклы:

1) исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган халык сәнгать һөнәрләре оешмаларына ярдәмне;

2) Осталар реестрына белешмәләр кертелгән халык сәнгать һөнәрләре осталарына финанс ярдәмен, мәгълүмати, консультатив ярдәмне, оештыру ярдәмен һәм Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка ярдәм чараларын.

5 статья. **Халык сәнгать һөнәрләрен саклауда, торгызуда һәм үстерүдә җирле үзидарә органнарының катнашуы**

1. Шәһәр җирлеге, муниципаль район, шәһәр округы җирле үзидарә органнары тиешенчә шәһәр җирлегендә, муниципаль районда, шәһәр округында халык сәнгать һөнәрләрен саклауда, торгызуда һәм үстерүдә катнаша.

2. Шәһәр җирлеге, муниципаль район, шәһәр округы җирле үзидарә органнары Осталар реестрына белешмәләр кертелгән халык сәнгать һөнәрләре осталарына финанс ярдәмен, мәгълүмати, консультатив ярдәмне, оештыру ярдәмен һәм Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль берәмлекләр уставларында каралган башка ярдәм чараларын күрсәтергә хокуклы.

6 статья. **Халык сәнгать һөнәрләре оешмалары**

1. Халык сәнгать һөнәрләре оешмалары эшчәнлегенең төп бурычы халык сәнгать һөнәрләре традицияләрен саклаудан, торгызудан һәм үстерүдән гыйбарәт.

2. Халык сәнгать һөнәрләре оешмаларына алар тарафыннан җитештереп җибәрелгән (җибәреп тору яисә башкача сату йә алмаштыру юлы белән реализацияләнергә тиешле) товарлар (үз көчләре белән башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр) күләмендә узган елга федераль дәүләт статистика күзәтүе белешмәләре буенча халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләре кимендә 50 процентны тәшкил иткән теләсә кайсы оештыру-хокукый рәвешендәге һәм милек рәвешендәге оешмалар (юридик затлар) керә.

3. Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы халык сәнгать һөнәрләре оешмалары турында белешмәләр ачык рәвештә таныша алу мөмкинлеге белән вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

7 статья. **Халык сәнгать һөнәре остасы**

1. Халык сәнгать һөнәре остасы үз эшчәнлеген юридик зат йә индивидуаль эшкуар белән төзелгән хезмәт шартнамәсе яисә граждан-хокук шартнамәсе шартларында гамәлгә ашырырга хокуклы.

2. Халык сәнгать һөнәре остасы үз эшчәнлеген индивидуаль эшкуар буларак гамәлгә ашырырга хокуклы.

3. Халык сәнгать һөнәре остасы үз эшчәнлеген, Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик зат буларак гамәлгә ашырырга хокуклы.

4. Индивидуаль эшкуар йә «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик зат буларак үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы халык сәнгать һөнәрләре осталары турында белешмәләр Осталар реестрына кертелә.

5. Осталар реестрындагы белешмәләр (таныша алу мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән белешмәләрдән тыш) ачык рәвештә таныша алу мөмкинлеге белән вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

8 статья. **Татарстан Республикасы территориясендә әзерләнә торган эшләнмәләрне халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләренә кертү**

1. Татарстан Республикасы территориясендә әзерләнә торган эшләнмәләрне халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләренә кертү халык сәнгать һөнәрләренең тапшырылган типлаштырылган үрнәкләрен һәм уникаль эшләнмәләрен карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган Халык сәнгать һөнәрләре сәнгать-эксперт советы карары нигезендә гамәлгә ашырыла. Мондый карар Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә расланучы халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләрен җитештерү төрләре һәм аларның төркемнәре исемлеге нигезендә кабул ителә.

2. Эшләнмәләрне халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләренә кертү мәсьәләләре буенча кабул ителә торган Халык сәнгать һөнәрләре сәнгать-эксперт советы карары (мондый карарда булган һәм таныша алу мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән белешмәләрдән тыш) ачык рәвештә таныша алу мөмкинлеге белән вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

9 статья. **Халык сәнгать һөнәрләре сәнгать-эксперт советы**

1. Халык сәнгать һөнәрләре сәнгать-эксперт советы үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган халык сәнгать һөнәрләре сәнгать-эксперт советы турындагы типлаштырылган нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган Халык сәнгать һөнәрләре сәнгать-эксперт советы хакындагы нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

2. Халык сәнгать һөнәрләре сәнгать-эксперт советы эшләнмәләрне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләрне башкара:

1) аларны халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләренә кертү турында карар кабул итә;

2) халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендәге эшчәнлекне экспертлар тарафыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

3) халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләре үрнәкләрен аларны халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләренең сәнгати кыйммәте танылган үрнәкләре буларак теркәү максатларында Халык сәнгать һөнәрләре федераль эксперт советына җибәрү турында карар кабул итә;

4) Халык сәнгать һөнәрләре сәнгать-эксперт советы турындагы нигезләмәдә билгеләнгән башка функцияләрне үти.

10 статья. **Халык сәнгать һөнәрләре традицион булган урыннар**

1. Халык сәнгать һөнәрләре традицион булган урыннар Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган халык сәнгать һөнәрләре традицион булган урыннарны билгеләү кагыйдәләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы раслаган халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләрен җитештерү төрләре һәм аларның төркемнәре исемлеге нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы халык сәнгать һөнәрләре традицион булган урыннар турында белешмәләр (танышa алу мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән белешмәләрдән тыш) ачык рәвештә таныша алу мөмкинлеге белән вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

3. Татарстан Республикасы халык сәнгать һөнәрләре традицион булган урыннар турында белешмәләр формалаштыру һәм алып бару тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган халык сәнгать һөнәрләре традицион булган урыннарның дәүләт реестрына кертелергә тиеш.

11 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип таныргa:

1) «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» 2005 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш);

2) «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2006 елның 17 февралендәге 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш);

3) «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 31 мартындагы

14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 3);

4) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 6 (II өлеш);

5) «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 5 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш).

12 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 18 июнь
№ 46-ТРЗ